КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2024 ел, 10 сентябрь | г.Казань | № 761

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы, дәүләт медицина оешмасы шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү нормативларын, норматив чыгымнарын һәм дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы, дәүләт медицина оешмасы шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү нормативларын;

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы, дәүләт медицина оешмасы шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнарын;

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы, дәүләт медицина оешмасы шартларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативларын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2024 – 2026 елларга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыру нормативларын, дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативларын раслау турында» 2023 ел, 6 сентябрь, 1086 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 6 сентябрь, 1086 нчы карары белән расланган 2024 – 2026 елларга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәренә үзгәреш кертү хакында» 2023 ел, 18 декабрь, 1635 нче.

3. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 10 сентябрь, 761 нче
карары белән расланды

## 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы, дәүләт медицина оешмасы шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү нормативлары

| Т/с | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативлары, кеше | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмаларына дәвалап бетерү (тернәкләндерү) – барлыгы, шул исәптән: | 4 722 | 4 722 | 4 722 |
| | миокардның кискен инфаркты, тотрыксыз стенокардия, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына операцияләр | 1 931 | 1 931 | 1 931 |
| | баш мие кан әйләнеше кискен бозылу | 582 | 582 | 582 |
| | умыртка сөяге үсешендә кимчелекләр һәм авырулар булганда, буыннарга пластика куйганда, очлыкларны эндопротезлаганда һәм реэндопротезлаганда, реплантация-ләгәндә ортопедик, травматологик операцияләр | 130 | 130 | 130 |
| | риск төркемнәрендәге йөкле хатын-кызлар авырулары | 1 758 | 1 758 | 1 758 |
| | шикәр диабеты | 321 | 321 | 321 |
| 2. | Эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры дәүләт медицина оешмаларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) – барлыгы, шул исәптән: | 880 | 880 | 880 |
| 2.1. | Яр Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | | | |
| | баш мие кан әйләнеше кискен бозылу | 314 | 314 | 314 |
| | умыртка сөяге үсешендә кимчелекләр һәм авырулар булганда, буыннарга пластика куйганда, очлыкларны эндопротезлаганда һәм реэндопротезлаганда, реплантация-ләгәндә ортопедик, травматологик операцияләр | 54 | 54 | 54 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 2.2. | «Әлмәт районара күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | | | |
| | миокардның кискен инфаркты, тотрыксыз стенокардия, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына операцияләр | 263 | 263 | 263 |
| | баш мие кан әйләнеше кискен бозылу | 84 | 84 | 84 |
| | риск төркемнәрендәге йөкле хатын-кызлар авырулары | 165 | 165 | 165 |
| | Барлыгы | 5 602 | 5 602 | 5 602 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 10 сентябрь, 761 нче
карары белән расланды

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы, дәүләт медицина оешмасы шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнары

| Т/с | Норматив чыгымнар исеме | Норматив чыгымнар, койка көненә сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 год |
| 1. | Миокардның кискен инфарктын, тотрыксыз стенокардияне, стационарда дәваланганнан соң, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына операцияләрдән соң турыдан-туры дәвалап бетерүгә (тернәкләндерүгә) чыгымнар | 2 461,67 | 2 574,87 | 2 692,93 |
| 2. | Баш мие кан әйләнеше кискен бозылуны стационарда дәваланганнан соң дәвалап бетерүгә (тернәкләндерүгә) чыгымнар | 2 449,84 | 2 562,50 | 2 679,99 |
| 3. | Умыртка сөяге үсешендә кимчелекләр һәм авырулар булганда, буыннарга пластика куйганда, очлыкларны эндопротезлаганда һәм реэндопротезлаганда, реплантацияләгәндә ортопедик, травматологик операцияләрдән соң турыдан-туры дәвалап бетерүгә (тернәкләндерүгә) чыгымнар | 2 418,24 | 2 529,43 | 2 645,42 |
| 4. | Куркыныч төркемнәрендәге йөкле хатын-кызлар авыруларын стационарда дәваланганнан соң дәвалап бетерүгә (тернәкләндерүгә) чыгымнар | 2 414,11 | 2 525,12 | 2 640,90 |
| 5. | Шикәр диабетын стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерүне (реабилитацияләүне) оештыруга чыгымнар | 2 406,36 | 2 517,02 | 2 632,44 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 10 сентябрь, 761 нче
карары белән расланды

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы, дәүләт медицина оешмасы шартларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативлары

| Т/с | Норматив исеме | Норматив күрсәткече, календарь көн | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 год |
| 1. | Миокардның кискен инфарктын, тотрыксыз стенокардияне, стационарда дәваланганнан соң, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына операцияләрдән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативы | 14 | 14 | 14 |
| 2. | Баш мие кан әйләнешенең кискен бозылуын стационарда дәваланганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативы | 14 | 14 | 14 |
| 3. | Умыртка сөяге үсешендә кимчелекләр һәм авырулар булганда, буыннарга пластика куйганда, очлыкларны эндопротезлаганда һәм реэндопротезлаганда, реплантацияләгәндә ортопедик, травматологик операцияләрдән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативы | 14 | 14 | 14 |
| 4. | Риск төркемнәрендәге йөкле хатын-кызлар авыруларын стационарда дәваланганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативы | 14 | 14 | 14 |
| 5. | Шикәр диабетын стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативы | 14 | 14 | 14 |